Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Березовая Грива торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елның 28 октябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлегенең Березовая Грива торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Березовая Грива торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны Борок авылында янгын сундеру машинасы өчен гараж төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) эшләренә юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлы авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарипов